| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУРНАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>КӨРНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Коры Корнәле ав.

24.10.2022 № 16

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының 26.11.2019 №41«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге милкендә булган , өченче затлар хокукыннан азат һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга тәңгәлләштерү һәм муниципаль мөлкәттән аренда шартларында нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, Көрнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек эшчәнлегенә шартлар булдыру максатларында, 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Мөлкәтне гамәлдән чыгару турында» 17.10.2022 ел № 9 күрсәтмәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге милкендә булган, өченче затлар хокукыннан азат һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегеннән түбәндәге мөлкәтне төшереп калдырырга:

- түбәндәге адрес буенча урнашкан элеккеге мәктәп бинасы: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Көрнәле авыл җирлеге, Коры Көрнәле авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт, гомуми мәйданы 1154,6 кв. м.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Көрнәле авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе** **Д.Б.Казакова**